2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авылы җирлеге Рус Акташы авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫКАРАРЫ

15 ноябрь 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегенең Рус Акташ авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Рус Акташы авыл җирлеге Рус Акташы авылы территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт юлларны ремонтлау).

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Рус Акташы авылы, Төзүчеләр ур., 14 йорттерриториясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Рус Акташы авыл җирлеге башлыгы С. А. Белоногов